КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь г.Казань № 1139

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәхси эшмәкәрләргә Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүгә озатулы ярдәм күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 15 август, 574 нче карары белән расланган Шәхси эшмәкәрләргә Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүгә озатулы ярдәм күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәхси эшмәкәрләргә Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүгә озатулы ярдәм күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 15 август, 574 нче карары белән расланган Шәхси эшмәкәрләргә Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүгә озатулы ярдәм күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«11. Конкурс юридик затларның һәм (яки) шәхси эшмәкәрләрнең индивидуаль тернәкләндерү яки абилитация программасында тәкъдим ителгән ярый торган (ярамый торган) хезмәт эшчәнлеге төрләрен исәпкә алып инвалидларны, шул исәптән югары, урта һөнәри белем, һөнәри уку, өстәмә һөнәри белем программалары буенча белем алуны тәмамлаган, эш белән тәэмин итүгә озатулы ярдәм күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга проектларын сайлап алу максатларында үткәрелә.

Проектлар түбәндәге чараларны күздә тотарга тиеш:

Татарстан Республикасы хезмәт базары анализын һәм инвалидлар өчен, шул исәптән белем алуны, укуны тәмамлаганнан соң белем бирү оешмаларын һәм укытуны гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаучылар өчен вакансияләрнең индивидуаль исемлеген төзү;

инвалидларны озатулы эш белән тәэмин итүне оештыру өчен белем бирү оешмаларын һәм укытуны гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаучы инвалидлар арасыннан максатчан аудиторияне алдан ук билгеләү өчен оешмалар белән бәйләнышларны оештыру;

инвалидларга индивидуаль һөнәри консультация бирүне, һөнәри сайлауны һәм сайлап алуны оештыру;

инвалидларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында ихтимал булган эш бирүчеләр белән алдан сөйләшүләр үткәрү;

эш бирүчеләр һәм инвалидлар белән сөйләшеп, инвалидны эшкә урнаштыру максатында эш бирүченең инвалидлар белән үзара мөнәсәбәтләрен оештыру, инвалидларга әңгәмәгә әзерләнүдә ярдәм күрсәтү, эш бирүче белән әңгәмә барышында инвалидны озата бару һәм аңа ярдәм күрсәтү;

инвалидка һөнәри уку һәм өстәмә һөнәри белем алу кирәклеген билгеләү һәм инвалидка һөнәри уку һәм өстәмә һөнәри белем алуда ярдәм күрсәтү;

инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып, аның эш урынына һәм эш бирүче оешма территориясе буенча хәрәкәт итү маршрутын формалаштыру;

эш бирүче оешманың инвалид өчен кирәкле ярдәмче бүлмәләрнең һәм мәгълүматның ачык булуын тәэмин итү;

эш бирүче оешмада махсус эш урынын коралландыру (җиһазландыру) буенча чараларны билгеләү;

хезмәт законнары нормаларын исәпкә алып инвалидлар өчен эш көне тәртибе үзенчәлекләрен билгеләү;

инвалид белән эшләүче эш бирүче оешма белгечләренә инвалидларга хезмәт бурычларын үзләштерүдә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү;

эш бирүче белән берлектә эш бирүче тарафыннан остазлыкны оештыру кирәклеген билгеләү һәм, кирәк булган очракта, эш бирүчегә остазлыкны оештыруда ярдәм күрсәтү, шул исәптән остазны инвалидның хезмәт бурычлары һәм эш шартлары белән таныштыру;

эшкә урнаштырылган инвалидларның эш урыннарында адаптация процессын анализлау, инвалидларга хезмәт бурычларын үтәүгә комачаулый торган гамәлдә булган адаптация проблемаларын һәм киртәләрне билгеләү, эш бирүче белән килештереп, инвалидның эш урынында билгеле булган адаптация проблемаларын

бетерүгә һәм аның һөнәри үсешенә һәм алга китешенә ярдәм итә торган чаралар системасын формалаштыру һәм гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәнфәгатьле органнары, инвалидларның иҗтимагый оешмалары, эш бирүчеләр вәкилләре катнашында проектны тормышка ашыру этаплары турында фикер алышу максатында квартал саен очрашулар үткәрү;

проектны тормышка ашыру барышын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;

проектны тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча инвалидларның иҗтимагый оешмалары, мәгариф оешмалары, эш бирүчеләр, мәнфәгатьле министрлыклар вәкилләре катнашында «түгәрәк өстәл» утырышы үткәрү;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында әйтелгән максатларга туры килә торган, инвалидларны эш белән тәэмин итүгә озатулы ярдәм күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру кысаларында тормышка ашыру өчен юридик зат һәм (яки) шәхси эшмәкәр мөстәкыйль тәкъдим иткән бүтән чаралар.

Проектта озатулы ярдәм күрсәтү буенча хезмәт күрсәтелә торган инвалидларның күздә тотылган саны, шул исәптән белем бирү оешмаларын һәм укытуны гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаучыларның кушма саны турында мәгълүмат булырга тиеш.

Проектта түбәндәге аны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булырга тиеш:

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында югары белем бирү программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында югары белем бирү программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында югары белем бирү программалары буенча белем алганнан соң алты һәм күбрәк ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем алганнан соң алты һәм күбрәк ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында һөнәри уку үткәннән соң өч ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында һөнәри уку үткәннән соң алты ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында һөнәри уку үткәннән соң алты һәм күбрәк ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында өстәмә һөнәр программаларны (квалификация күтәрү программаларын һәм яңадан һөнәри әзерләү программаларын) үзләштергәннән соң өч ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше;

озатулы эшкә урнаштыру буенча хезмәт күрсәтү алган инвалидларның гомуми санында өстәмә һөнәр программаларны (квалификация күтәрү программаларын һәм яңадан һөнәри әзерләү программаларын) үзләштергәннән соң алты ай эчендә эш тапкан эшкә урнашкан инвалидлар өлеше.

Нәтиҗәлелек күрсәткечләре мәгънәләре Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар кысаларында эшкә урнашканда яшь инвалидларны озата бару буенча үрнәк программаны раслау турында» 2017 ел, 23 август, 625 нче боерыгы нигезендә исәпләнә;

38 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше агымдагы финанс елында проектны тормышка ашыру вакыты тәмамланган көннән соң 30 көн эчендә, әмма агымдагы финанс елының 1 декабреннән дә соңга калмыйча субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемендә кире кайтарылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин